РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ БОЛЬШЕКИБЯЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422065, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Большие Кибячи, ул.Ф.Энгельса, 21
тел. (84362) 42-6-24

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КИБӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422065, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Кибәче авылы, Ф.Энгельс урам, 21 йорт
тел. (84362) 42-6-24

e-mail: Bkib.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
04.07.2023

КАРАР
№18

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» 2009 елның 19 февралендә 1а номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Саба районы Прокуратурасының 26.06.2023 №02-08-02-2023/482-23-20920031 протесты нигезендә, Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1.«Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» 19.02.2009 ел №1а Олы Кибәче авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында Нигезләмәгә (алга таба текст буенча - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.1. пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа бишенче абзац белән тулыландырырга:

« - Россия Федерациясе Кораллы көчләрен, башка гаскәрләрне, хәрби формалаштыру һәм органнарны тыныч вакыттан сугыш вакытына күчерү буенча чараларны тәэмин итү өчен, мобилизация чорында һәм аларның кирәкле дәрәҗәдә комплектлануын тәэмин итү өчен запаста булган хәрби-укытылган гражданнарның кирәкле санын әзерләү буенча планлы эш алып бару.»;

1„2. Нигезләмәнең III бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

« III. Функцияләр.

3.1 Беренчел хәрби исәп документларында булган мәгълүматларны җыюны, саклауны һәм эшкәртүне оештыру һәм тәэмин итү максатыннан, хәрби-хисәп хезмәткәре:

а) запаста булган гражданнарны һәм хәрби хезмәтка чакырылырга тиешле, аларның территориясендә яшәүче яки (өч айдан артык срокка) булган гражданнарны беренчел хәрби исәпкә ала;

б) эчке эшләр органнары белән берлектә үз территориясендә яшәүче яки (өч айдан артык срокка) булган һәм хәрби исәпкә куелырга тиешле гражданнарны ачыклый;

в) үз территориясендә булган оешмаларны исәпкә ала һәм аларда хәрби исәп-хисап алып баруны контрольда тота:

г) беренчел хәрби исәп документларын машина белан язу һәм электрон төрләрдә алып бара һәм саклый.

3.2. Беренчел хәрби исәп документларындагы мәгълүматларны актуаль хәлдә тоту һәм хәрби исәп документларындагы мәгълүматларны актуаль хәлдә тотуны тәэмин итү максатыннан, хәрби-хисап хезмәткәре:

а) беренчел хәрби исәп документларын тиешле муниципаль берәмлек хәрби комиссариатларның һәм оешмаларның хәрби исәп документлары белән елына 1 тапкырдан да сирәгрәк булмаган күләмдә чагыштыра;

б) беренчел хәрби исәп документларындагы мәгълүматларга үз вакытында узгәрешләр кертә һәм ике атна эчендә хәрби комиссариатларга кертелгән узгәрешләр турында хәбәр итә;

в) оешмаларның вазыйфаи затларына һәм гражданнарга Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән хәрби исәп, мобилизацион әзерлек һәм мобилизация буенча бурычларын аңлата, аларның үтәлешен контрольдә тота, шулай ук күрсәтелгән бурычларны үтәмәгән өчен жаваплылык турында хәбәр итә;

г) ике атна эчендә муниципаль берәмлекләрнең тиешле Хәрби комиссариатларына оешмаларның вазыйфаи затлары һәм гражданнарның хәрби исәп, мобилизацион әзерлек һәм мобилизация буенча бурычларын үтәмәү очраклары турында мәгълүмат тапшыра.

Беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашырганда хәрби-хисәп хезмәткәре «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында»гы Федераль закон белән билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълумати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/kibiachi адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Олы Кибәче авыл җирлеге башлыгы А.К.Сафин